КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 11 май г.Казань № 685

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле экспертлык ярдәмен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 26 декабрь, 1210 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле экспертлык ярдәмен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7.7 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.4 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «субсидияне кире кайтару өчен» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару өчен» сүзләренә алмаштырырга, «субсидияне кире кайтаруны тәэмин итә» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтаруны тәэмин итә» сүзләренә алмаштырырга, «субсидияне кире кайтару турында» сүзләрен «субсидия акчасын кире

кайтару турында» сүзләренә алмаштырырга;

8.5 пунктта татар текстында «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган уникаль экосистеманы Иннополис шәһәрендә төзүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 13 февраль, 78 нче карары белән расланган Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган уникаль экосистеманы Иннополис шәһәрендә төзүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7.6 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.4 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «субсидияне кире кайтару өчен» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару өчен» сүзләренә алмаштырырга, «субсидияне кире кайтаруны тәэмин итә» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтаруны тәэмин итә» сүзләренә алмаштырырга, «субсидияне кире кайтару турында» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару турында» сүзләренә алмаштырырга;

8.5 пунктта татар текстында «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы<br>Премьер–министры А.В.Песошин